- Балалар - бәхет, аларда шатлык, ышаныч, хыяллар һәм киләчәк, - ди Торбеево проселогында яшәvче кvпбалалы ана Ильмира Равиль кызы Пестова. Ул «Йолдызчык» дигән балалар бакчасында тәрбияче булып хезмәт итә. - Оч пар сине яратучы бала кулы кочканда барлыкка килгән шатлык хисен бернәрсә дә алыштыра алмый.
Ильмира Равиль кызы гади хезмәткәрләр гаиләсендә тәрбия-ләнгән. Әнисе - Нурия Әхмәт кызы Узбекова, гомере буе Торбеево мясокомбинатында эшли, ә әтисе – Равиль Хасян улы Узбеков бvгенге конгә кадәр ДРСУда хезмәткәре. Алар кызларын аерым жылы могаләмәдә тәрбиялиләр. Кызлар да бер-берсен анлашып, бер-берсе турында кайгыртып vсәләр. Әти-әниләрендәге ин жылы монәсәбәтне кызлар vзләрендә гомер буена саклыйлар.   Тату гаиләдә балаларга тиешле тәрбия бирелә, профессия vзләштерәләр. Ике сенел бvген мәгариф олкәсендә тырышып хезмәт итәләр. Әмма Ильмира, сенелесенә караганда, мәгарифкә бормалы озын юлдан килә. Торбеево беренче урта мәктәбен тәмамлагач, Торбеeводагы ит һәм сот промышленносте колледжына укырга керә.Уку йортын кызыл дипломга тәмамлый Ильмира Равилевна. Укыган колледжында эшкә дә кала һәм шул ук вакыт Мәскәv технология һәм идарә университетына укырга кереп югары белемле була.
Озакламый Ильмира Равиль кызы, 2005 елны, Михаил Николай улына киявгә чыга. Тиздән беренчеләре – Русланнары туа. Бала туу белән гаиләдә яна мәшәкатьләр барлыкка килә, әмма яшь гаилә жилкәсенә бу авыр булмый һәм 2009 елны Вадим исемле икенче балалары доньяга килә. Ә 2013нче елда оченче тапкыр әни була. Андрей дип топчекләренә исем бирәләр. Бvген алар гаиләсендә оч Ватан сакчысы vсә.
Һәрбер кvпбалалы ананын тосле, Ильмира Равил кызынын да эше житәрлек: ойне чисталыкта тотарга, зур гаиләгә аш-су әзерләргә, кер юу, vтvкләv һәм башка санап бетергесез эш. Балаларында да шул ук сыйфатларны тәрбияли яшь ата-ана. Бvген олы уллары - әниләренен ярдәмчеләре, кечкенәләре олыларыннан калмаска тырыша. Балалар әти-әниләре йозенә тап тошермиләр. Ой эшләрендә алар да тәртипне яраталар, мәктәптә тырышып укыйлар. Руслан алтынчы класста укый. Әйбәт укуы белән бергә, спорт белән шогыльләнә, футбол уйный, командасы белән торле ярышларда катнаша. Техника белән дә дус, чонки уртанчы энесе Вадим белән гаражда әтиләренә торле машиналарны тозәтергә булышалар. Сигез яшьлек Вадим - ижади шәхес, ул рәсем ясарга ярата. Биш яшьлек топчек Андрей бик тә кызыксынучан: тирә-якны ойрәнергә ярата, конструктор жыя, әбисе белән китаплар укый. Балаларнын һәрберсенен vз

кызыксындырган олкәсе бар. Әниләре балалары тормышынын бер мизгелен дә игътибарсыз калдырмый, барлык эшләреннән хәбәрдар: унышлары һәм унышсызлыклары турында белә. Алар белән бергә шатлана, яхшылыкка ойрәтә, бер-берсенә ярдәм итv турында сойли.
Ильмира Равиль кызы Пестова балалар ярата. Мәктәпкәчә тәрбия буенча педагогик квалификация vзгәртv курсыларын тәмамлау турында диплом ала. Шулай тәрбияче булып китә. Ул Торбееводагы «Йолдызчык» дигән балалар бакчасында тәрбияләгән балалары турында да бик кайгыра. Нәни кешене тәрбияләvдә, аны шәхес итеп формалаштыруда балалар бакчасынын ифрат зур роль уйнавы һәркемгә мәгълvм. Биредә бала башлап коллективта яшәргә, яшьтәшләре белән аралашырга, олкәннәрне ихтирам итәргә ойрәнә. Шуна да балалар бакчасынын кирәклеге жәмгыятьтә бәхәс тудырмый, анын бала тормышында моһим урын тотканын һәркем яхшы анлый. Бvген «Куянкайлар» группасына 3-4 яшьлек балалар йори. Бәләкәчләргә аерым якын килеп эшләргә туры килә, чонки алар чынлап та бик кечкенәләр. Кон саен олы мәхәббәт, игътибар, тырыш хезмәт таләп итә алар. Ильмира ханым тынгысыз мәктәпкәчә балаларны һәм сайлаган профессиясен бик тә ярата. Тыныч, ягымлы Ильмира Равиль кызы тиктормас баларга тавышын беркайчан кvтәрми. Чонки балалар белән эшләv ана шатлык китерә. Ул: «Балалар белән эшләргә яратам, аларнын һәр конне ниндидер ачыш ясауларын, vсvләрен, нәрсәгәдер ойрәнvләрен кvрv зур куаныч. Сабыйларнын бакчада тәрбияләнгән чорында кvнелләренә матурлык, илсоярлек, татулык, ярдәм-челлек, дуслык тойгысы салырга омтылам» .
Бу югары максатка ирешv очен тәрбияченен фәкать тырышлыгы, ихласлыгы, эшен мокиббән китеп яратуы, бала кvнелен анлый белvе, донья серләренә тошендерергә омтылуы ярдәм итә. Эзләнvчән, тынгысыз тәрбияче Ильмира Равиль кызы Пестова һәрчак яна идеяләр белән янып яши. Сайлаган һонәренә тугры.

Наилә Насырова